| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

14.02.2023　　　　　　　　　　№ 185-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 07 февралендәге 134-п номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнехановның 2022 елның 14 декабрендәге ПР-268 номерлы йөкләмәләре исемлеге нигезендә Саба муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының «Саба муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2023 елның 07 февралендәге 134-п номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. Схеманы түбәндәге эчтәлекле 97 пункт белән тулыландырырга:

«

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 97 | Байлар Сабасы ш.т.б., «Ямьле Саба» Сабинка яр буе елгасы, чараны үткәрү территориясе | азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар, азык-төлек продуктлары, аттракционнар | 3500 кв.м га кадәр. | бәйрәм, иҗтимагый-сәяси, мәдәни-массакүләм һәм спорт-массакүләм чаралар уздырганда | |

».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча : http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районының рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад бүлеге башлыгы М.М. Бaһмановка йөкләргә.

Җитәкче　　　　　　　　　　М.Р. Ишниязов